| ГЛАВА ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

7 октябрь 2024 ел № 2

Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа
авылында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 18 октябре 17.00 сәгатьтә ТР Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен уздыру урыны итеп Тойгуҗа авылы, Үзәк урам, 48 йорт адресы буенча урнашкан Тойгуҗа авыл мәдәният йортын билегләргә
2. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

"Сез 2025 елда җыелган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
«1. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Тойгуҗа авылы скважинасы өчен 1 (бер) данә насос сатып алу).
2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (комплектта янгын гидранты сатып алу; Тойгуҗа авылында янгын гидранты урнаштыру).
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү: (Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу).»

3. Әлеге карарны Тойгуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, кабул ителгән көннән алып 10 көн дәвамында Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә www.mendeleevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сафин